РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.05.2019 № 509-п

Саба муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2018 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен үтәүнең, башкару дисциплинасының торышы һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеге турында” 2010 ел, 20 апрель, 324 нче карары нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен расларга (теркәлә).

2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен расларга (теркәлә).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче: М.Р. Ишниязов

РАСЛАНДЫ:
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
“____” ___. 2019 ел _____
номерлы карары белән

# САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ ТӨРЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕН АЛЫП БАРУ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге тәртип “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару процедурасын билгели.

2. “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге түбәндәге белешмәләрнең системалаштырылган исемлеге булып тора:

а) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре турында;

б) муниципаль берәмлекнең муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контрольнең тиешле төрләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемнәре турында;

в) муниципаль контрольнең тиешле төрен җайга салучы Россия Федерацисе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларының реквизитлары турында;

3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Исемлекне раслау, исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү, белешмәләрне исемлектән төшереп калдыру Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә.

5. Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү яисә белешмәләрне исемлектән төшереп калдыру өчен “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына тиешле эшчәнлек өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирә торган хокукый нормаларның гамәлдә булуы туктатылуы яисә үзгәрүе турында норматив хокукый акт кабул итү нигез булып тора.

6. Исемлек түбәндәге формада алып барыла.

“Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару формасы

| N п/п | “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исеме | “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | Муниципаль контрольнең тиешле төрен җайга салучы Россия Федерацисе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, “Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларының реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | | | |

РАСЛАНДЫ:
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының

“____” ___. 2019 ел _____
номерлы карары белән

# МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| № п/п | Күрсәткечләр | Исәпләү методикасы | |
|---|---|---|---|
| 1 | Узган елга караганда муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда профилактик чаралар саны үсеше, % | еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %**, монда<br><br>A - агымдагы елда үткәрелгән профилактик чаралар саны;<br>B - узган елда үткәрелгән профилактик чаралар саны. |
| 2 | Төзекләндерү кагыйдәләрен бозган очракта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү фактларының кимүе, % | еллык күрсәткеч | **V = (A / B- A1 / B1) x 100 %**, монда<br><br>A - узган елда төзекләндерү муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны, бер. (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 ст.);<br>A1 - агымдагы елда төзекләндерү муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны, бер. (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 ст.);<br>B - узган елда үткәрелгән пландагы рейдлар саны (системалы мониторинг) бер.;<br>B1- агымдагы елда үткәрелгән пландагы рейдлар саны (системалы мониторинг) бер.; |
| 3 | Муниципаль районлагы контроль төрләренең гомуми санына карата аларны гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, % | еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %**, монда<br><br>A - муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча кабул ителгән административ регламентлар саны;<br>B - расланган муниципаль контроль төрләре |